Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл Советы

КАРАРЫ

26 июнь 2024 ел                                                                                    № 113

Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 53 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, үзләренең вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә

Габдрахман авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 53 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2018 елның 05 декабрендәге 57 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 8 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 62 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 73 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Әлмәт муниципаль районының Габдрахман авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба - Тәртип) хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары» кушымтасының I бүлегенең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Башлык, башлык урынбасарының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә муниципаль берәмлек башлыклары өчен хезмәткә түләүнең унберенче төркемнә кертелгән

нормативтан артып китә алмый - елына 14,12 айлык акчалата түләү, аларның урынбасарлары өчен - елына 14,5 айлык акчалата бүләкләү.»;

1.2. Тәртипнең II бүлеге 7 пунктының 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфасының исеме | Вазыйфаи оклад (11 төркем өчен хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19 985 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 19 585» |

1.4. Карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегендә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфасының исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (11 төркем өчен хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 19 991 |
| Башлык урынбасары | 14 366» |

2. Әлеге карарны Әлмәт районы,Габдрахман авылы, Советлар урамы, 75 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Габдрахман
авыл җирлеге Башлыгы — Р.Г.Мифтахов